**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Якушкино авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**"2023елның 20 апреле** **№55**

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

59 статьяның 3 пункты нигезендә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Якушкино авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә туләттерелеп бетерелмәгән өлешне һәм бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсе дә мираска хокуклы булмаса яисә барлык варислар мирастан баш тартсалар һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын игълан итмэгән булса;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч еллык срок узуы;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Җирле салымнар буенча түләттерелеп бетерелмәгән өлешне һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2021 елның 28 апрелендәге 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендә мәгълүмат такталарында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.Ф.Зиятдинов